ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**2016 елның 22 апреле**

Зеленодольск
шәһәре

**КАРАР**
**№ 1051**

2016 елның икенче яртыеллыгына Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында айлык балалар йөрү билетын бирү тәртибе турында

2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 20 статьяның 5 пунктындагы 1 пунктчасы, Россия Федерациясе Бюджет кодексының 86 статьяның 1 пункты нигезендә, Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. Зеленодольск муниципаль районының Гари поселогында һәм Загородная урамында яшәүче гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 сыйныф укучыларына айлык балалар юл билетын бүлүне билгеләргә.
2. Зеленодольск муниципаль районының «Волна» микрорайонында яшәүче күпбалалы гаиләләрдән гомуми белем бирү оешмаларының 1-11 сыйныф укучыларына айлык балалар юл билетын бүлүне билгеләргә.
3. 2016 елның 01 гыйнварыннан 2016 елның 31 декабренә кадәр Зеленодольск муниципаль районы бюджеты хисабына бер укучыга ай саен 500 сум 00 тиен күләмендә балалар юл билетын сатып алу чыгымнарын тормышка ашырырга.
4. «Зеленодольск муниципаль районының финанс-бюджет палатасы» МУ җитәкчесенә Зеленодольск муниципаль районы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре нигезендә гомуми белем бирү оешмаларында айлык юл билетын бирү чыгымнарын финанслауны гамәлгә ашырырга.
5. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары - мәгариф идарәсе башлыгына айлык балалар юл билетын бүлүнең үтәлешен исәпкә алуны һәм тикшереп торуны тәэмин итәргә.
6. Гомуми белем бирү оешмалары директорларына айлык балалар юл билетын сатып алу эшен оештырырга, бүлеп бирелгән акчаларны максатчан файдалануны тәэмин итәргә.

7. Зеленодольск муниципаль районы Советының җәмәгатьчелек һәм ММЧ белән элемтә бүлеге башлыгы А.Н. Коршуновка әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А.Х. Сәхибуллин